**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» 01 **2019 ЕЛ** Болгар шәһәре № 63

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру һәм аларны 2019 елның язында Россия Федерациясе Кораллы Көчләр сафларына озатуны уздыру турында

“Хәрби хезмәт һәм хәрби бурыч турында” 1998 елның 28 мартындагы 53нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру турындагы Положениене раслау турында” 2006 елның 11 ноябрендәге 663нче Карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Хәрби-табиблык экспертизасы турындагы положениене раслау турында” 2013 елның 4 июлендәге 565нче Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы гражданнарын хәрби хезмәткә чакыруны вакытында һәм оешканлык белән үткәрү максатында, ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитеты чыгарган

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елның 1 апреленнән 15 июльгә кадәр запаста булмаган һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру белән бәйле чараларны уздырырга.
2. “Спас хастаханәсе” нең баш табибына йөкләргә:
- хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле егетләргә медицина тикшерүе уздыру өчен медицина комиссиясен табиб-белгечләр (терапевт, хирург, неврапотолог, психиатр, оториноларинголог, стоматолог, дерматовенеролог, офтальмолог, нарколог) һәм урта медицина персоналы белән тәэмин итәргә;
- медицина комиссиясен РФ Оборона министрлыгының 2006 елның 16 октябрендәге 420нче Боерыгы нигезендә, барлык медико-санитария кирәк-яраклары белән тәэмин итәргә;
- Татарстан Республикасының Әлки һәм Спас районнары хәрби комиссариатына хезмәткә алынырга тиешле, диспансерлык учетында булган кешеләр исемлеген, шулай ук соңгы 12 айда йогышлы авырулар белән авырган кешеләр исемлеген, профилактика прививкасы һәм медикаментоз

чараларны кичерә алмаучылар турында мәгълүмат, амбулатор авыруның медицина картасын, станционар авыруның медицина картасыннан күчермәләрне, рентгенограммаларны, тикшерүнең махсус ысуллары турындагы беркетмәләрне һәм гражданнарның сәламәтлеге торышын чагылдырган башка медицина документларын тәкъдим итәргә;

- Болгардагы “Олимп” спорт мәктәбе базасында егетләргә медицина тикшерүе уздыруны оештырырга;

- призывникларга өстәмә медицина тикшерүе уздыру өчен Спас хастаханәсендә тиешле ятак-урын карарга һәм призывникларның тулысынча тикшеренү узуын тәэмин итәргә;

3. Райондагы учреждение, предприятие, оешма җитәкчеләренә, авыл җирлеге башлыкларына тәкъдим итәргә:

- төп эш урыны буенча бер ай вакытка айлык уртача хезмәт хакын саклап, техник хезмәткәрләр бүлеп бирергә;

- хәрби хезмәткә китәргә җыенган егетлтрне чакыру пунктына китерү һәм командалар составында Татарстан Республикасы хәрби комиссариатына илтү өчен транспорт бүлеп бирергә;

- хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга хәрби комиссариатка бару кирәклеге турында хәбәр итәргә;

- хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның хәрби комиссариатка вакытында килүен тәэмин итәргә;

4. Егетләрне Россия Федерациясе Кораллы Кэчләре сафларына озатканда хәрби комиссаритта җәмәгать тәртибен һәм иминлекне тәэмин итүне РФ Эчке эшләр министрлыгының Спас районы буенча бүлеге җитәкчесенә йөкләргә (озату планы нигезендә).

5. Татарстан Республикасының Әлки һәм Спас районнары буенча хәрби комиссарга йөкләргә:

- “Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында”гы Федераль законның 4нче маддәсе нигезендә, чакырылыш комиссиясенә килергә кирәклеге турында гражданнарга райондагы авыл җирлеге башкарма комитетлары, оешма, предприятие, учреждеиеләр һәм уку йортлары җитәкчеләре аша белгертүне оештырырга;

- ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге педагог-психологын җәлеп итеп, гражданнар белән профессиональ психологик тикшерү уздырырга (хәрби учет чараларын үткәрү графигы нигезендә);

- хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны хәрби хезмәткә җибәрү буенча төзелгән график нигезендә Татарстан Республикасының җыелу пунктына алып килергә;

- хәрби комиссариатта армиягә китәргә тиешле егетләр белән хәрби-патриотик эш алып барырга.

6. Татарстан Республикасының Әлки һәм Спас районнары буенча хәрби комиссарына, Эчке эшләр министрлыгының Спас районы буенча бүлеге җитәкчесенә, ОУФМСның Спас районындагы җитәкчесенә, ЗАГС органнары җитәкчесенә:

- хәрби учет чараларына килми торган гражданнарны эзләү буенча бердәм эш планын килештерергә;
- хәрби комиссариатка килми торган гражданнарга, повестканы тапшыру мөмкинлеге булмаган гражданнарга карата гамәлдәге закон нигезендә тиешле чаралар күрергә;
- уздырылган чаралар, башкарылган эшләр турында тиешле вакытта районның чакыру комиссиясенә хәбәр итәргә;

7. ТР Спас муниципаль районының хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенә йөкләргә:

- хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга карата медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча гамәлдәге закон нигезендә карар кабул итәргә;
- хәрби хезмәткә чакырырудан баш тарткан гражданнарга карата материалларны аларны җаваплылыкка тарту максаты белән тиешле органнарга җибәрергә;
- ТР Спас муниципаль районының яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге, ТР Әлки һәм Спас районнары хәрби комиссариаты, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге белән берлектә Призывник көнен уздырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үзем йөклим.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Осокин